Проект

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә дәүләт йомгаклау аттестациясе**

ТАРИХ буенча төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары
**кодификаторы**

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнде



**ТАРИХ буенча төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторы**

Тарих буенча төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторы (алга таба – кодификатор) контроль үлчәү материалларының (алга таба – КҮМ) структурасын һәм эчтәлеген билгеләүче документларның берсе булып тора. Кодификатор чыгарылыш укучылары әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр һәм һәр объектка туры килүче мәгълүм коды булган тикшерелүче эчтәлек элементларының системага салынган исемлегеннән гыйбарәт.

Кодификатор Төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компоненты базасында (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2004 елның 5 мартындагы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми мәгариф дәүләт стандартлары федераль компонентын раслау турында» 1089 номерлы боерыгы) төзелде. Кодификаторга кертелгән эчтәлек элементларын төгәлләштерү Тарих буенча төп гомуми мәгариф үрнәк программасында бар.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Кодификатор ике бүлектән тора:

– 1 бүлек. «ТАРИХ буенча төп дәүләт имтиханында тикшерелүче эчтәлек элементлары исемлеге»;

– 2 бүлек. «ТАРИХ буенча төп гомуми белем бирүнең гомумбелем программаларын үзләштергән укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге».

Кодификаторга стандартның «Төп белем бирү программалары эчтәлегенең мәҗбүри минимумы» бүлегендә курсив белән аерып куелган эчтәлек элементлары кертелмәгән: әлеге эчтәлек өйрәнелергә тиеш, ләкин стандартның «Чыгарылыш укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр» бүлегенә кертелмәгән, ягъни контроль объекты булып тормый. Шулай ук кодификаторга чыгарылыш укучылары әзерлеге дәрәҗәсенең дәүләт йомгаклау аттестациясе кысаларында аларга ирешүне тикшерү мөмкин булмаган таләпләре кертелмәгән.

**1 бүлек. «ТАРИХ буенча төп дәүләт имтиханында тикшерелүче эчтәлек элементлары исемлеге»**

Кодификаторның беренче баганасы бүлекнең кодын, темаларын күрсәтә. Икенче баганада эчтәлек элементлары бар, алар өчен тикшерү биремнәре төзелә. «*» *тамгасы белән гомуми тарих буенча белемнәрне*

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



*җәлеп итеп тикшерелүче эчтәлек элементлары билгеләнә.* Өченче баганада имтихан эшендә тикшерелүче эчтәлек элементлары күрсәтелә. Калын курсив белән түбәндә ваграк элементларга бүлгәләнгән эре эчтәлек блоклары күрсәтелгән.

| Бүлек, тема коды | Контрольдәге элемент коды | Имтихан эше биремнәре белән тикшерелүче эчтәлек элементлары |
|---|---|---|
| **1** | | ***Борынгы заман һәм Урта гасырлар*** |
| | 1.1 | *Борынгы заманда безнең ил территориясендәге халыклар һәм дәүләтләр* |
| | 1.1.1* | Безнең эрага кадәр I меңъеллык уртасына Россия территориясндәге халыклар |
| | 1.1.2* | Көнчыгыш славяннар: таралып утырулары, күршеләре, шөгыльләре, җәмгыять строе. Тәңречелек |
| | *1.2.* | *Рус дәүләте IX гасырда – XII гасыр башларында* |
| | 1.2.1* | Новгород һәм Киев – борынгы рус дәүләтчелеге үзәкләре. Борынгы рус дәүләтенең оешуы |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | |
|---|---|---|
| | 1.2.2* | Владимир I. Русьнең чукындырылуы |
| | 1.2.3* | Ярослав Мудрый. Русская Правда. Владимир Мономах |
| | *1.3* | *XII гасырда – XV гасыр уртасында рус җирләре һәм княжьлекләре* |
| | 1.3.1 | Русьтә сәяси таркаулык |
| | 1.3.2* | XIII гасырда тышкы агрессиягә каршы көрәш. Монгол яулап алулары. Көнбатыш экспансиясе. Александр Невский |
| | 1.3.3* | Рус җирләрен берләштерә башлау. Иван Калита |
| | 1.3.4* | Дмитрий Донской. Куликово сугышы |
| | 1.3.5 | Русьнең иҗтимагый тормышында чиркәүнең роле. Сергий Радонежский |
| | *1.4* | *XV гасырның икенче яртысында – XVII гасырда Россия дәүләте* |
| | 1.4.1* | Алтын Урда хакимлегеннән котылу. Иван III. Рус җирләрен берләштерүнең тәмамлануы |
| | 1.4.2 | Россия дәүләте хакимият органнары оешу. 1497 елгы Хөкем китабы |
| | 1.4.3 | Иван IV Грозный. Патша хакимияте урнашу. XVI гасыр уртасы реформалары. Земство соборлары. Опричнина |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | |
|---|---|---|
| | 1.4.4* | Дәүләт территориясенең киңәюе (Казан һәм Әстерхан ханлыкларын, Көнбатыш Себерне кушу) |
| | 1.4.5* | Фетнәле заман. Тышкы экспансиягә каршы көрәш. К. Минин, Д. Пожарский |
| | 1.4.6 | Россия беренче Романовлар идарәсе чорында |
| | 1.4.7 | 1649 елгы Собор уложениесе. Крепостной хокукның юридик яктан рәсмиләштерелүе |
| | 1.4.8 | Чиркәүнең бүленүе. Никон һәм Аввакум |
| | 1.4.9 | XVII гасырның икенче яртысында социаль хәрәкәтләр. Степан Разин |
| | 1.4.10* | XVII гасырда Россиянең тышкы сәясәте. Сулъяк Украинаның Россия составына керүе |
| | *1.5* | *Борынгы гасырлардан алып XVII гасырның ахырына кадәр илебез халыклары мәдәнияте* |
| | 1.5.1* | Борынгы рус мәдәнияте формалашу: фольклор, язма әдәбият, рәсем сәнгате, архитектура |
| | 1.5.2* | Россия дәүләтенең мәдәнияте формалашу. Елъязма. Андрей Рублев. Китаплар басу. Иван Фёдоров |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | |
|---|---|---|
| **2** | | ***Яңа чор*** |
| | *2.1* | *Россия XVIII гасырда – XIX гасыр уртасында* |
| | 2.1.1 | XVIII гасырның беренче чирегендәге үзгәрешләр. Пётр I. Абсолютчылык |
| | 2.1.2* | Даими армия һәм флот төзелү. Төньяк сугышы |
| | 2.1.3 | Сарай түнтәрелешләре. Дворянчылыкның хокукларын һәм өстенлекләрен киңәйтү |
| | 2.1.4* | Екатерина II нең «Мәгърифәтчелек абсолютчылыгы». Катлауларга бүленешнең рәсмиләштерелүе |
| | 2.1.5 | Социаль хәрәкәтләр. Е.И. Пугачёв |
| | 2.1.6* | Россия XVIII гасырның икенче яртысындагы сугышларда. А.В. Суворов, Ф.Ф. Ушаков |
| | 2.1.7 | XIX гасырның беренче яртысында эчке сәясәт. М.М. Сперанский |
| | 2.1.8* | 1812 елгы Ватан сугышы |
| | 2.1.9 | Декабристлар хәрәкәте |
| | 2.1.10* | XIX гасырның икенче чирегендә иҗтимагый фикер үсеше. Дәүләтнең рәсми идеологиясе. Көнбатышчылар һәм славянофиллар |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | |
|---|---|---|
| | 2.1.11* | Сәнәгать яңарышы башлануы |
| | 2.1.12* | Кавказны буйсындыру. Кырым сугышы |
| | *2.2.* | *Россия XIX гасырның икенче яртысында – XX гасыр башында* |
| | 2.2.1 | 1860-1870 еллардагы реформалар. Александр II. Крепостной хокукның бетерелүе |
| | 2.2.2* | Сәнәгать яңарышының тәмамлануы. Эшчеләр сыйныфы формалашу |
| | 2.2.3* | XIX гасырның икенче яртысында иҗтимагый хәрәкәт |
| | 2.2.4* | Россия хәрби-сәяси блокларда |
| | 2.2.5* | Сәнәгый үсеш. Монополияләр формалашу. С.Ю. Витте |
| | 2.2.6* | Рус-япон сугышы |
| | 2.2.7 | Модернизация шартларында социаль каршылыкларның кискенләшүе. 1905-1907 еллардагы революция. Дәүләт думасы |
| | 2.2.8 | П.А. Столыпин. Аграр реформа |
| | *2.3* | *XVIII гасырда – XX гасыр башында Россия мәдәнияте* |
| | 2.3.1* | Мәдәниятнең дөньяви төс алуы. Россия һәм дөнья мәдәниятенең үзара |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | |
|---|---|---|
| | | бәйләнеше һәм үзара йогынтысы |
| | 2.3.2* | Фән һәм мәгариф. М.В. Ломоносов, Н.И. Лобачевский, Д.И. Менделеев |
| | 2.3.3* | Әдәбият һәм сәнгать |
| **3** | | ***Иң яңа тарих*** |
| | *3.1* | *1914-1991 елларда Россия – СССР* |
| | 3.1.1* | Россия Беренче бөтендөнья сугышында |
| | 3.1.2* | Россиядә 1917 елгы революция. Монархиянең бетерелүе. Вакытлы хөкүмәт һәм Советлар |
| | 3.1.3 | 1917 елның октябрендә Совет власте игълан ителү. В.И. Ленин |
| | 3.1.4* | Большевиклар сәясәте һәм берпартияле диктатура урнаштырылу. Россия империясенең таркалуы |
| | 3.1.5* | Гражданнар сугышы. Кызыллар һәм аклар. «Хәрби коммунизм» |
| | 3.1.6* | Яңа икътисадый сәясәт. СССР оешу |
| | 3.1.7 | Социализм төзү юлларын эзләү. Үзәкләштерелгән (команда) икътисад формалаштыру. Индустриальләштерү. Авыл хуҗалыгын коллективлаштыру. Рухи тормышта зур үзгәрешләр |
| | 3.1.8 | Партия-дәүләт аппараты хакимияте. И.В. Сталин. Массакүләм репрессияләр |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | |
|---|---|---|
| | 3.1.9* | СССР 1920-1930 еллардагы халыкара мөнәсәбәтләр системасында |
| | 3.1.10* | СССР Икенче бөтендөнья сугышында. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышының башы, этаплары, зур сугышлары. Мәскәү өчен сугыш |
| | 3.1.11* | Сталинград сугышы. Курск дугасында сугыш. Сугыш барышында тамырдан үзгәреш |
| | 3.1.12* | Сугыш елларында советлар тылы. Партизаннар хәрәкәте. СССР Гитлерга каршы коалициядә |
| | 3.1.13* | Басып алучыларны совет җиреннән куып чыгару |
| | 3.1.14* | Бөек Ватан сугышының нәтиҗәләре. Совет полководецлары. Г.К. Жуков |
| | 3.1.15 | Сугыштан соң хуҗалыкны аякка бастыру |
| | 3.1.16* | «Җепшеклек». КПССның XX съезды. Н.С. Хрущев |
| | 3.1.17* | «Торгынлык». Л.И. Брежнев. Совет системасының кризис кичерүе |
| | 3.1.18* | 1945-1980 елларда СССРның тышкы сәясәте. Салкын сугыш. «Йомшару» |
| | 3.1.19 | «Үзгәртеп кору». «Тизләнеш» стратегиясенең каршыклары һәм |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | |
|---|---|---|
| | | уңышсызлыклары. Сәяси тормышны демократлаштыру. М.С. Горбачев |
| | 3.1.20 | 1991 елның августы вакыйгалары. СССРның таркалуы. БДБ оешу |
| | 3.1.21* | Әдәбият һәм сәнгатьтә социалистик реализм. Совет мәгарифе, фән һәм техника казанышлары |
| | 3.2 | *Хәзерге заманда Россия* |
| | 3.2.1 | Суверен дәүләт буларак Россия Федерациясе оешу |
| | 3.2.2* | Б.Н. Ельцин. Базар сәясәтенә күчү. Россия Федерациясе Конституциясен кабул итү |
| | 3.2.3* | Россия Федерациясе 2000-2012 елларда: илнең хәзерге заманда социаль-икътисадый һәм иҗтимагый-сәяси үсеше төп тенденцияләре. В.В. Путин. Д.А. Медведев |

**2 бүлек. ТАРИХ буенча төп гомуми белем бирү гомуми белем программаларын үзләштергән укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге**

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

Чыгарылыш укучылары әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге Төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компонентының «Чыгарылыш укучылары әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр» бүлеге нигезендә төзелде.

Таблицаның беренче ике баганасында таләпләр коды бирелгән, өченчесендә – ирешелүе чыгарылыш укучыларының ТДИ барышында тикшерелүче әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр.

| Таләпләр коды | | Чыгарылыш укучылары әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр |
|---|---|---|
| ***1*** | | ***Белергә (аңларга):*** |
| | 1.1 | Россия һәм дөнья тарихының борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр төп даталары, этаплары һәм хәлиткеч вакыйгалары |
| | 1.2 | Ватаныбыз һәм гомуми тарихның иң күренекле эшлеклеләре |
| | 1.3 | тарихи үсеш барышында формалашкан иң мөһим мәдәният казанышлары һәм кыйммәтләр системасы |
| | 1.4 | тарихи чыганакларның өйрәнелгән төрләре |
| ***2*** | | ***Белергә тиеш:*** |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | |
|---|---|---|
| | 2.1 | Ватаныбыз тарихы һәм гомуми тарих вакыйгалары даталарын шул гасыр белән **чагыштырырга** |
| | 2.2 | Ватаныбыз тарихы һәм гомуми тарихның мөһим вакыйгаларының эзлеклелеген һәм дәвамлылыгын **билгеләргә** |
| | 2.3 | сорауларга җавап биргәндә, уку барышында төрле мәсьәләләрне чишкәндә **тарихи һәм заманча чыганаклар мәгълүматларын файдаланырга**; төрле чыганаклар мәгълүматларын чагыштырырга |
| | 2.4 | тарихи картада халыклар таралышы, дәүләтләр чикләре, шәһәрләрне, мөһим тарихи вакыйгалар **урыннарын күрсәтергә** |
| | 2.5 | мөһим тарихи вакыйгалар һәм аларда катнашучылар турында, кирәкле фактларны, даталарны, терминнарны белүгә нигезләнеп **сөйләргә** |
| | 2.6 | текст һәм иллюстрация материаллары, тарихи чыганаклар фрагментлары нигезендә тарихи вакыйгаларга һәм |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | |
|---|---|---|
| | | мәдәният һәйкәлләренә **тасвирлама бирергә** |
| | 2.7 | алган белемнәрне **планнар төзегәндә һәм иҗади эшләр** (шул исәптән сочинениеләр) **язганда** файдаланырга |
| | 2.8 | гомуми тарихи процессларның һәм аерым фактларның **үзара бәйләнешен чагыштырып карарга** |
| | 2.9 | тарихи процессларның, күренеш һәм вакыйгаларның **җитди сыйфатларын ачыкларга** |
| | 2.10 | тарихи күренешләрне һәм вакыйгаларны бирелгән билгеләр буенча **төркемнәргә бүлергә** |
| | 2.11 | өйрәнгән тарихи төшенчәләрнең һәм терминнарның **мәгънәсен аңлатырга** |
| | 2.12 | чагыштырылучы тарихи вакыйгалар һәм күренешләрнең **охшашлыкларын** һәм **аерымлыкларын ачыкларга** |
| | 2.13 | Иң мөһим тарихи вакыйгаларның **сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен ачыкларга** |
| | 2.14 | Россия тарихы һәм гомуми тарихның аеруча мөһим вакыйгаларына һәм шәхесләренә, илебез һәм дөнья |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | |
|---|---|---|
| | | мәдәнияте казанышларына **үз мөнәсәбәтеңне аңлатырга** |
| ***3*** | | ***Алынган белемнәрне һәм осталыкны гамәли эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта түбәндәгеләр өчен файдаланырга:*** |
| | 3.1 | хәзерге заман тормышы вакыйгалары һәм күренешләренең тарихи сәбәпләрен һәм тарихи әһәмиятен аңлауда |
| | 3.2 | Россия халыклары һәм дөнья халыклары тарихи мирасы турында үз фикереңне әйтүдә |
| | 3.3 | тарихи урнаштырылган социаль тәртип нормаларын аңлатканда |
| | 3.4 | башка мәдәният, милләт һәм дин вәкилләре белән аралашканда |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте